КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 февраль г.Казань № 63

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарны читләштерү һәм аеруча куркыныч хайваннар чыганакларын бетергәндә терлек продуктларын алу турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен, хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авыруларында хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе хакында аңлатманы раслау турында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юкка чыгарганда хайваннарны алуны үткәрү кирәклеге турында» 2020 елның 29 октябрендәге чыг-5017 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы территориясендә кош гриппының югары патогенлы вирусы чыккан урыннар барлыкка килүне булдырмау һәм бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентының “Африка дуңгызлар чумасы белән авыручы кыргый кабаннар авыруына һәм аны тарату куркынычы янауга бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә чикләү чараларын (карантин) билгеләү турында” 2021 елның 26 гыйнварындагы ПУ-56 номерлы Указының 2 пунктындагы “а” һәм “б” пунктчаларында билгеләнгән территориядә терлекләрне аерып алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрергә.

2. Хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны гамәлгә ашыру буенча махсус комиссия составын (карарга теркәлә) расларга.

3. Хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны гамәлгә ашыру буенча махсус комиссиягә бу карарның 1 нче пункты белән күздә тотылган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 8 февраль, 63 нче
карары белән расланды

Хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны гамәлгә ашыру буенча махсус комиссия составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Махсус комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Галимуллин Айрат Наил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Әлмәт территориаль дәүләт ветеринария инспекциясе бүлеге башлыгы |
| Гатин Идрис Мөдәрис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Гыйрфанов Марат Нил улы | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Реваль Рөстәм улы | «Әлмәт район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы. |
| Ногманов Илдар Нургали улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары |

_______________________